**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы**
**мәгариф һәм фән**
**министры**
**___________ И.Г.Һадиуллин**
**«___» _________ 2023 нче ел**

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең**
**рус телле укучылары өчен 2023 нче елда**
**туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру**
**материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант**
**контрольных измерительных материалов для проведения в 2023 году**
**государственной итоговой аттестации (ГИА)**
**по родному (татарскому) языку**
**для русскоязычных учащихся школ с русским языком обучения**

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# Рус телендә белем бирү мәктәпләренең рус телле укучылары өчен 2023 нче елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Татар теленнән төп дәүләт имтиханын тапшыру өчен, 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә. Имтихан эше **33 биремне** үз эченә алган **4** бүлектән тора. **1 нче бүлектәге** 13 бирем (1 – 13 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. **2 нче бүлектәге** 7 бирем (14 – 20 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә. **3 нче бүлектәге** 8 бирем (21 – 28 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала. **4 нче бүлектәге** 29 – 32 нче биремнәр сөйләм ситуациясенә караган татарча репликалар язуны күздә тота. Ачык типтагы **33 нче бирем** укучыларның язма сөйләмен тикшерүгә юнәлдерелгән.

**Уңышлар телибез!**

## Инструкция по выполнению работы

Время, отведенное на выполнение заданий – 3 часа 55 минут (235 минут). Экзаменационная работа по татарскому языку состоит из четырех разделов, включающих 33 задания. **Раздел 1** (задания по аудированию) включает 13 заданий на понимание аутентичных текстов (задания 1 - 13). **Раздел 2** (задания по чтению) включает в себя 7 заданий (задания 14 - 20). **Раздел 3** (задания по лексике и грамматике) состоит из 8 заданий (задания 21 - 28). **Раздел 4** (задания по письменной речи) состоит из 4 заданий на написание реплик по предложенной коммуникативной ситуации (задания 29 – 32) и задания, в котором предлагается написать личное письмо (задание 33).

**Желаем успеха!**

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Айсылуның нишлисе бар?**

1) әтисенә бүләк аласы бар.
2) татар шагыйрьләре турында сөйлисе бар.
3) китап кибетенә барасы бар.

**2** **Дуслар шимбә көнне кая барырга җыеналар?**

1) ял паркына
2) кибеткә
3) кинога

**3** **Рәшит кем булырга хыяллана?**

1) табиб
2) диңгезче
3) укытучы

**4** **Айсылу кайсы команданың җанатары?**

1) "Рубин"
2) "Арсенал"
3) "Ак бүре"

**5** **Рәшит Сабан туенда нинди уенда катнашкан?**

1) капчык белән сугышу
2) капчык киеп йөгерү
3) чүлмәк вату

**6** **Айсылу нишләргә ярата?**

1) идән юарга
2) гөлләргә су сибәргә
3) ашарга пешерергә

**7** **Рәшитнең җәен кайда ял итәсе килә?**

1) тарихи шәһәрдә
2) диңгездә
3) тауларда

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Дуслар яраткан фәннәре турында сөйләшәләр.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Саматның химик буласы килә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Алсуга телләр өйрәнү күбрәк ошый.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Алсу биш тел белә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Саматның инглизчә беләсе килми.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Алсу дуслары белән төрле телләрдә аралаша.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**Раздел 2**

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

| Текст | Сорау |
|---|---|
| “Урам” экстрим-паркына чакырабыз!<br>15 нче августта паркта беренче балалар урам мәдәнияте фестивале узачак. Бу көнне экстремаль спорт төрләре һәм бию баттлары буенча мастер-класслар һәм ярышлар, бокс буенча тренировкалар узачак. Барлык чараларда 6 – 16 яшьлек балалар катнаша ала. Чараларда катнашу бушлай, теркәлү урында уздырыла. Җиңүчеләрне һәм призёрларны оештыручылардан бүләкләр көтә.<br>Фестиваль 13.00 сәгатьтә башлана. Теләүчеләр өчен ачык һавада уен мәйданчыгы эшләячәк. | **Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**<br>1) Ял паркында уздырылачак түләүсез уеннар турында.<br>2) “Урам” паркында үтәчәк чарага чакыру турында.<br>3) Бию баттлары буенча тренировкалар турында. |

**15**

| Текст | Сорау |
|---|---|
| Яшь башкаручылар бәйгесенә рәхим итегез!<br>Быел Рәшит Ваһапов исемендәге Халыкара татар җыры фестивалендә яшь башкаручылар бәйгесе үтәчәк. Анда югары һәм урта уку йортларында укучы җырчылар катнаша ала. Гаризалар 10 нчы апрельгә кадәр кабул ителә. Чараның йомгаклау этабы 24 нче апрельдә узачак. | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Яшь җырчылар бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләү турында.<br>2) Яшь җырчылар бәйгесенең нәтиҗәләре турында. |

| | |
|---|---|
| Җиңүчеләрне тантаналы төстә татар җыры фестиваленең гала-концертында бүләкләячәкләр. Бәйгенең шартлары белән фестивальнең сайтында танышырга була.<br>Белешмәләр өчен: 231-18-28. | 3) Яшь җырчылар арасында үткәреләчәк бәйге турында. |

**16**

| | |
|---|---|
| Хәерле көн, Әмир! Хәлләрең яхшымы? Кышкы каникулда ничек ял иттең?<br>Мин каникулда шәһәребездә булдым, беркая да бармадым, чөнки ял вакытында дзюдо буенча шәһәр беренчелеге узды. Син беләсең бит, мин берничә ел инде бу спорт төре белән шөгыльләнәм. Бу ярышларда командабыз 2 тапкыр җиңде. Мин үзем дә шәхси беренчелектә өченче урын алдым. Призлы урын алуыма мин дә, тренерым да бик шатландык. Җиңүчеләргә дипломнар тапшырдылар. Беренче һәм икенче урыннарны алган көндәшләрем бик көчле иде, шуңа күрә алга таба миңа тагын да күбрәк шөгыльләнергә кирәк.<br>Син ял вакытында нәрсәләр белән шөгыльләндең? Миңа җавап яз, көтәм.<br>Сәлам белән дустың Кәрим. | **Электрон хатында Кәрим дустына нәрсә турында язган?**<br>1) Кышкы ялда шәһәр беренчелегендә катнашуы һәм җиңә алмавы турында.<br>2) Ял вакытында спорт төрләре белән шөгыльләнүе турында.<br>3) Шәһәр беренчелегендә уңышка ирешүе турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Сигезенче сыйныф малайлары, дәрес бетүгә, мәктәп ишегалдында футбол уйныйлар. Былтыр рәхәт иде, алты малай ике төркемгә бүленәләр дә, әниләре телефоннан шалтыратып чыгырганчы, футбол уйныйлар.

Быел бер малайлары икенче мәктәпкә күчкәч, бик кайгырыштылар, ләкин сыйныфларына яңа малай килгәнен белгәч, «Ур-ра!» кычкырдылар. Ләкин башкаларга караганда озынрак буйлы, зур кара күзле, матур гына сөйләшүче Рөстәм малайларның өметен акламады. Дәресләр бетүгә, ул тиз генә җыена да көн саен өенә ашыга. Уйнарга, йөгерергә яратмый дияр идең, физкультура дәресендә аңа тиңнәр юк. Башка дәресләрдә дә һрвакыт җавап бирә, саран да түгел, ярдәмчел дә.

Инде сыйныф җитәкчесенә дә зарланып карадылар. Рөстәм башкалар белән аралашырга яратмый диделәр. Аннары өенә барывп карарга булдылар.

—Китап укып утыра микән? Компьютерда футбол уйныйдыр әле. Чигү чигеп утырмаса!

Рөстәм яшәгән подъезд ишеге ачык иде, малайлар, шау-гөр килеп, эчкә атылдылар. Лифт эшләмәвен белгәч, борчылдылар — сигезенче катка җәяү менәселәре килмәде.

Баскычтан көлешә-көлешә менгәндә малайлар кинәт туктап калдылар. Өске каттан, авыру әбисен күтәреп, Рөстәм төшеп килә иде.Сыйныфташларын күргәч:

- Дәү әнинең аяклары авырта. Мәктәптән кайткач, без бергә саф һавага чыгабыз, - диде малай.

Малайларга бик уңайсыз булып китте. (*А. Әхмәтгалиевадан*)

**17** Малайлар нишләргә яраталар?
1) Дәрестә кул күтәреп җавап бирергә.
2) Дәрестә эндәшми утырырга.
3) Дәрестән соң футбол уйнарга.

**18** Сигезенче сыйныф егетләре нәрсәгә сөенәләр?
1) Сыйныфташлары яңа мәктәпкә күчүгә.
2) Сыйныфка яңа укучы килүгә.
3) Яңа сыйныфташлары бик акыллы егет булуга.

**19** Рөстәм нишли?
1) Һәр көн тиз генә өенә кайтып китә.
2) Һәр көн кичкә кадәр футбол уйный.
3) Һәр көн компьютерда футбол уйный.

**20** Малайлар нәрсә беләләр?
1) Сыйныфташларының китап укырга яратуын.
2) Сыйныфташларының авыру әбисе барлыгын.
3) Сыйныфташларының футбол уйнарга яратмавын.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Ике күрше яшәгән, ди: берсе бик бай, икенчесе бик ярлы икән. Бай күршеләр кичке ашны ашамыйлар, чәй эчәләр дә тыныч кына йокларга (21) … икән. Ә ярлы күршеләрнең балалары күп булган, шуңа күрә (22) … гел җыр – бию, елау – көлү тавышлары ишетелә икән. Бу (23) … бай бик гаҗәпләнгән. Үз – үзенә: “Боларның ашарга да, кияргә дә бернәрсәләре юк, үзләре бик шат яшиләр, - ди икән. - Ә безнең байлыгыбыз шулкадәр күп, әмма шат (24) …”.

Беркөн бу бай ярлы күршесеннән сорый:

- Сез ничек шулай шат яшисез?

Теге ярлы моңа әйтә:

- Безнең җиде алтын (25) … бар, без шулар белән уйныйбыз, - ди.

Шуннан бу бай егерме алтын алма сатып ала.

- Хәзер без дә шат яшәрбез, - ди ул (26) … .

Ләкин күп генә тырышмасыннар, бу алтын алмалар бай (27) … шатлык китерми.

Кич белән бай үзенең ярлы күршесенә кунакка керә һәм күрә: җиде баланың кайсысы бии, кайсысы җырлый, кайсылары уйный, кайберсе үзара сугыша.

Шуннан бай ярлы күршесенә:

- Синең байлык минем (28) … күбрәк икән, - ди. *(Татар халык әкияте)*

**21** 1) ятарга 2) яталар 3) ятмыйлар

**22** 1) аларның 2) аларга 3) алардан

**23** 1) хәлгә 2) хәлдән 3) хәлдә

**24** 1) яшибез 2) яшәмибез 3) яшәргә

**25** 1) алмалар 2) алмаларыбыз 3) алмабыз

**26** 1) хатынга 2) хатынына 3) хатыныннан

**27** 1) гаиләсенең 2) гаиләгә 3) гаиләсенә

**28** 1) байлыктан 2) байлыкка 3) байлыкның

## Раздел 4

***В заданиях 29-32 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**29** Сообщите одноклассникам, что на следующей неделе в школе состоится встреча с молодыми татарскими поэтами.

**30** Спросите у друга (подруги), какие школьные предметы нравятся ему (ей) больше всего и почему.

**31** Предложите младшему брату сходить в воскресенье в новый детский IT парк.

**32** Посоветуйте своим родителям посетить выставку «Татарский костюм» в Казанском Кремле.

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**

**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Мин буш вакытымны файдалы үткәрергә тырышам. Дәресләрдән соң дусларым белән саф һавада йөрим, атнага ике тапкыр спорт секциясенә йөрим, ә ял көннәрендә кинога яки кунакка барам. Кичләрен Интернеттан яңалыклар укыйм, әти-әнием белән аралашам.*

*... Ә син буш вакытыңны ничек уздырасың?... Ял көннәрендә кая барырга яратасың? ... Кичләрен нәрсә белән шөгыльләнәсең?*

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**

**Беренче сорау. Айсылуның нишлисе бар?**

**Айсылу:** Сәлам, Рәшит!

**Рәшит**: Хәерле көн, Айсылу! Дәресләрдән соң бергә кайтабызмы?

**Айсылу**: Юк шул, дәресләрдән соң кибеткә барасым бар. Ял көнне әниемнең туган көне, аңа бүләк аласым бар.

**Рәшит**: Кайсы кибеткә барырга телисең? Нәрсә бүләк итәргә уйладыңмы инде?

**Айсылу**: Уйладым. Иң яхшы бүләк – китап, диләр. Мин дә әниемә шигырьләр җыентыгы бүләк итәргә булдым.

**Рәшит**: Әниеңә кайсы шагыйрьләрнең иҗаты ошый соң?

**Айсылу:** Ул классик әдипләрнең иҗатын да ярата, заманча шагыйрьләрнең шигырьләрен дә кызыксынып укый. Яраткан шагыйре – Разил Вәлиев. Аның китабын бүләк итәрмен дип уйлыйм. Ә син кая барырга җыенасың? Әйдә, кибеткә бергә барабыз. Миңа ярдәм итәрсең. Вакытың бармы?

**Рәшит:** Бар. Сөйләштек.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Дуслар ял көнне нишләргә җыеналар?**

Рәшит: Айсылу, шимбә көнгә планнарың бармы? Нишләргә җыенасың?

Айсылу: Белмим әле, бүген чәршәмбе генә бит. Ә син нишләргә уйлыйсың? Өйдә ял итеп утырасың килмиме? Бәлки кинога барырбыз?

Рәшит: Юк. Көннәр бик матур тора, саф һавада йөрисе килә. Аннары яңгырлар башланачак, һава торышы үзгәрәчәк. Анда инде кинога да барырга мөмкин.

Айсылу: Әйе, син хаклы, көннәр җылы вакытта урамнан керәсе дә килми.

Рәшит: Шуңа күрә ял көнне мин сине паркка барырга чакырам. Көн буе анда рәхәтләнеп ял итә алабыз. Анда фонтаннар, аллеялар искиткеч матур! Велосипедлар, скейтбордлар өчен махсус юллар ясалган. Аларны прокатка алып торырга мөмкин.

Айсылу: Ярар, Рәшит, чакыруың өчен рәхмәт. Мин риза. Сәгать ничәдә очрашабыз? Нинди транспортта барабыз?

Рәшит: Минемчә, автобус уңайлы булыр. Ул троллейбустан тизрәк бара. Әйдә, 14.00 сәгатьтә мәктәп янында очрашыйк.
Айсылу: Яхшы, сөйләштек. Әле шимбәгә кадәр вакыт бар. Ниндидер эшләр килеп чыкса, вакытын үзгәртербез.
Рәшит: Килештек.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**
**Өченче сорау. Рәшит кем булырга хыяллана?**
Рәшит: Айсылу, мәктәпне тәмамлагач, син кем булырга хыялланасың?
Айсылу: Кызык сорау! Төгәл белмим әле. Миңа табиб һөнәре ошый. Ә синең хыялың нинди, Рәшит? Сиңа кайсы һөнәр күбрәк ошый?
Рәшит: Минем хыялым бар. Минем диңгезче буласым, зур диңгезләрдә йөзәсем килә.
Айсылу: Хыялың зур икән. Диңгезче булу өчен, кайда махсус белем алырга кирәк соң? Безнең шәһәрдә андый уку йортлары бармы?
Рәшит: Интернеттан карап таптым инде, Санкт-Петербургтагы Нахимов училищесына керергә кирәк. Башка шәһәрләрдә дә шундый училищелар бар.
Айсылу: Син 9 нчы сыйныфтан соң китәргә җыенасыңмы? Әти-әниең беләләрме инде? Алар бит укытучылар. Син дә укытучы булырсың дип уйлыйлардыр.
Рәшит: Әйе, китәсем килә. Юк әле, аларга әйтмәдем. Әни каршы булыр дип уйлыйм. Мине башка шәһәргә җибәрәсе килмәс.
Айсылу: Хыялың тормышка ашсын, Рәшит! Син бик яхшы укыйсың. Барысы да яхшы булыр!
Рәшит: Бик зур рәхмәт сиңа, дустым.
**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Айсылу кайсы команданың җанатары?**
Рәшит: Айсылу, сәлам, син кая барасың?
Айсылу: Сәлам, Рәшит! Дус кызым белән сәгать биштә очрашырга сөйләштек. Аннары без аның белән бергә “Ак Барс Арена” стадионына барабыз. Ә син кая ашыгасың?
Рәшит: Мин бокс секциясенә йөрим бит, “Ак бүре” спорт комплексына. Минем дә сәгать биштә тренировка башлана. Шуңа өлгерәсем килә, соңга калырга ярамый. Тренерыбыз бик таләпчән.
Рәшит: Ә сез нәрсә карарга барасыз?
Айсылу: Футбол карарга барабыз. Бүген “Рубин” белән “Арсенал” уйный. Мин дә, дустым да - безнең команданың җанатарлары.
Рәшит: Кызык! Белмәгән идем. Сиңа футбол уены шулай ошыймы?
Айсылу: Бик ошый. Минем әтием – футболчы бит. Мин кечкенәдән футбол карап үстем. Хәзер дә безнекеләр уйнаганда, стадионга барырга тырышам.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Рәшит Сабан туенда нинди уенда катнашкан?**
Рәшит: Айсылу, синең Сабан туенда булганың бармы?
Айсылу: Әйе, мин кечкенә булганда, әби белән бабайга авылга кайта идем, алар белән Сабан туена да бара идек.
Рәшит: Ә Казан Сабан туенда булганың бармы?
Айсылу: Юк. Ә син үзең кайда булдың? Сиңа Сабан туе ошадымы?
Рәшит: Минем әби белән бабай Казанда яшиләр, шуңа күрә мин шәһәр Сабан туенда гына булдым. Бәйрәм миңа бик ошады. Без төрле ярышлар карадык: ат чабышы, көрәш. Бәйрәмдә балалар өчен дә уеннар була. Алар да бик кызыклы. Мәсәлән, капчык киеп йөгерү, капчык белән сугышу.
Айсылу: Ә син үзең дә катнаштыңмы соң?
Рәшит: Әйе, бер тапкыр чүлмәк вату уенында катнаштым.
Айсылу: Бүләк бирделәрме?
Рәшит: Әйе, уенчык машина бирделәр.
**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Айсылу нишләргә ярата?**
Рәшит: Айсылу, син өйдә әти-әниеңә булышасыңмы?
Айсылу: Әлбәттә, Рәшит. Ял көннәрендә без әнием белән өй җыештырабыз. Ә син әти-әниеңә ничек ярдәм итәсең?
Рәшит: Мин дә аларга һәрвакыт булышырга тырышам. Әти командировкада булганда, әнием миңа кибеткә барырга һәм ашамлыклар алырга куша. Шулай ук тренировкаларым булмаган көннәрдә мин балалар бакчасыннан сеңелемне алып кайтам. Әнием аны алырга өлгерми, ул эштән соң кайта.
Айсылу: Син бик яхшы ярдәмче икән. Әле кичләрен сеңелең белән төрле уеннар да уйныйсыңдыр, шулаймы? Синең белән уйнарга яратамы?
Рәшит: Әйе, дәресләремне әзерләгәч, без аның белән шакмаклардан өйләр, биналар төзибез, рәсем ясыйбыз.
Айсылу: Менә ничек яхшы.
Рәшит: Ә сиңа өйдәге эшләрдән кайсылары күбрәк ошый? Идән юарга яратасыңмы? Тузан сөртергәме? Әллә ашарга пешерергәме?
Айсылу: Әйе, мин бу эшләрне эшлим, ләкин яраткан эшем – гөлләргә су сибү.
Рәшит: Менә хәзер белдем инде. Бик кирәкле эш.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Рәшитнең җәен кайда ял итәсе килә?**
Рәшит: Айсылу, имтиханнар беткәч, син ничек ял итәргә уйлыйсың?
Айсылу: Әбием белән бабам авылда яшиләр. Алар мине бик көтәләр. Шуңа күрә имтиханнардан соң башта аларга кунака кайтырмын дип уйлыйм. Ә син җәйге ялны кайда үткәрергә телисең?
Рәшит: Мин – боксчы бит. Имтиханнар бетүгә, спорт лагерена китәрмен. Гадәттә, без анда өч атна булабыз. Ул Казаннан ерак түгел, бик матур урында, урман эчендә урнашкан.
Айсылу: Аннан кайткач, кайларга барасың килә?
Рәшит: Әти-әнием, гадәттә, июль ахырында ял алалар. Ел саен без гаиләбез белəзн сәяхәткә китәбез. Без Калининградта, Карелиядә, Абхазиядә булдык. Быел инде Дагыстанга барасыбыз килә, чөнки безгә таулар бик ошый.
Айсылу: Сез чын сәяхәтчеләр икән. Күп урыннарда булгансыз, диңгездә дә, тарихи шәһәрләрдә дә ял иткәнсез.
Рәшит: Әйе, сәяхәт итү бик кызык. Яңа җирләрне, истәлекле урыннарны күрәсең, яңа кешеләр белән танышасың. Ә син, Айсылу, авылдан соң кая барырга җыенасың?
Алия: Быел әниемнең ялы сентябрь аенда гына була, шуңа күрә башка җирләргә бара алмыйбыз, дачада гына булырбыз дип уйлыйм.
Рәшит: Ялларыбыз яхшы үтсен!
Айсылу: Рәхмәт!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Самат: Исәнме, Алсу!

Алсу: Сәлам, Самат! Әйт әле, мәктәптә сиңа кайсы дәресләр ошый?

Самат: Миңа информатика һәм химия ошый.

Алсу: Шулаймыни?

Самат: Әйе. Минем программист буласым килә, шуңа күрә информатика дәресләренә бик яратып йөрим. Химия дәресләре дә бик ошый, чөнки анда төрле реактивлар, химик матдәләр белән танышабыз. Син үзең дә беләсең бит, мин тәҗрибәләр ясарга бик яратам.

Алсу: Әйе, химия дәресләре күп егетләргә ошый.

Самат: Ә син нәрсә белән кызыксынасың, Алсу? Кайсы дәресләр синең өчен иң кызыклы?

Алсу: Мин телләр өйрәнергә яратам, шунлыктан рус, татар, инглиз теле дәресләре миңа бик кызык. Дәресләрдән соң төрек теле курсларына да йөрим әле.

Самат: Минемчә, телләр өйрәнү бик авыр…

Алсу: Әйе. Ләкин бик кызыклы. Күп телләр белгән саен, дусларың да арта. Минем дусларым арасында төрле милләт кешеләре бар: татарлар, руслар, төрекләр.

Самат: Син алар белән ничек таныштың?

Алсу: Мәктәптә, урамда, курсларда, җәйге тел лагеренда таныштым. Алар да төрек телен өйрәнергә килгәннәр иде.

Самат: Син алар белән еш аралашасыңмы?

Алсу: Әйе, Интернеттан аралашабыз, хатлар языша быз, скайп аша сөйләшәбез.

Самат: Русчамы?

Алсу: Бер көнне - русча, икенче көнне – инглизчә, өченче көнне - төрекчә. Хәзер алар татарча да өйрәнә башладылар.

Самат: Шулаймыни? Ә ничек?

Алсу: Онлайн дәресләр аша. Татар телен өйрәнү өчен, “Ана теле” онлайн мәктәбе бар бит. Аларга җанлы аралашу дәресләре бик ошый, һәм тиздән татарча сөйләшә алырлар дип уйлыйм.

Самат: Бик кызык! Мин дә бу мәктәп турында дусларыма әйтермен. Аларның да татарча беләселәре килә.

Алсу: Әйдә, киләсе атнада мин сине алар белән таныштырам, Самат. Син аларга химик реакцияләр турында инглизчә сөйләрсең. Инглиз телен яхшы белү өчен, сиңа бик яхшы тәҗрибә булачак.

Самат: Шәп! Мин риза! Инглизчә тагын да яхшырак белермен.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Внесите ответы в бланк ответов.**

## Татар теле буенча имтихан эшен бәяләү системасы

1-28 нче биремнәрдә дөрес күрсәтелгән һәр җавап 1 балл белән бәяләнә. Җаваплар биремнәрне үтәү күрсәтмәсендәгечә язылган булса һәм дөрес җавап үрнәге белән тулысынча туры килсә, бирем дөрес үтәлгән дип санала.

**ҖАВАПЛАР**

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 3 |
| 2 | 1 |
| 3 | 2 |
| 4 | 1 |
| 5 | 3 |
| 6 | 2 |
| 7 | 3 |
| 8 | 1 |
| 9 | 2 |
| 10 | 1 |
| 11 | 2 |
| 12 | 2 |
| 13 | 1 |
| 14 | 2 |
| 15 | 3 |
| 16 | 3 |
| 17 | 3 |
| 18 | 2 |
| 19 | 1 |

| | |
|---|---|
| 20 | 2 |
| 21 | 2 |
| 22 | 3 |
| 23 | 1 |
| 24 | 2 |
| 25 | 3 |
| 26 | 2 |
| 27 | 3 |
| 28 | 1 |

## 29-32 нче биремнәрне бәяләү критерийлары

Сөйләм ситуациясенә караган репликалар язу. 29-32 нче биремнәр максималь 2 балл белән бәяләнә.

*1 нче таблица*

| *№* | *Бәяләү критерийлары* | *Баллар* |
|---|---|---|
| *I* | *Язылган текстның эчтәлеге* | |
| К1 | Сөйләм ситуациясенә караган репликаны формалаштыру | |
| | Имтихан бирүче, сөйләм ситуациясенә караган репликаны аңлап, җавабын дөрес формалаштырган. Коммуникатив бурыч төгәл үтәлгән.<br>Фактик хаталар юк. | 1 |
| | Имтихан бирүче сөйләм ситуациясенә караган репликаны дөрес формалаштырмаган.<br>***Яки*** Сөйләм ситуациясенә караган реплика өлешчә генә формалаштырылган<br>***Яки*** дөрес формалаштырмаган.<br>***Яки*** Фактик хаталар бар. | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| | ***Яки*** Имтихан **бирүче башка сөйләм ситуациясенә караган реплика язган**. | |
| *II* | *Грамоталылык* | |
| К2 | Орфография һәм сөйләм нормаларының үтәлеше | |
| | Репликада орфографиягә тел нормаларының үтәлешенә караган (грамматик, орфографик, стилистик. пунктуацион) хаталар юк.<br>***Һәм/ яки*** төрле нормаларга караган 2 хата бар. | 1 |
| | Репликада тел нормаларының үтәлешенә караган 3 яки күбрәк хата бар.<br>***Яки*** Имтихан **бирүче башка сөйләм ситуациясенә караган реплика язган**. | 0 |
| Язма эш өчен максималь балл | | 2 |

## 33 нче биремне бәяләү критерийлары

## Шәхси хат язу биремен бәяләү критерийлары

*2 нче таблица*

| К | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| К1 | Коммуникатив бурычны үтәү | ***Эш тулысынча башкарылган:*** 3 сорауга да тулы җавап бирелгән. Мөрәҗәгать итү, саубуллашу һәм имзалау фразалары дөрес сайланган.<br>Алынган хатка рәхмәт белдерелгән | ***Эш башкарылган:*** 3 сорауга да җавап бирелгән, әмма берсенә бирелгән җавап тулы түгел. Хат стилен бозган 1-2 төгәлсезлек бар ***һәм/яки***<br>алынган хатка рәхмәт белдерелмәгән | ***Эш өлешчә башкарылган***: 2 сорауга гомуми җавап бирелгән, әмма 1 сорауга бирелгән җавап тулы түгел ***яки*** бер сорауга гомумән җавап юк. Хат стилен бозган 3 яки күбрәк төгәлсезлек бар, итагатьлелек | ***Эш башкарылмаган:*** 2 сорауга җавап бирелмәгән ***яки*** текстның күләме тулмый |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | формалары сакланмаган | |
| К2 | Текстны оештыру | | Текст логик эзлеклелектә төзелгән һәм абзацларга бүленештә хаталар юк; тел чаралары дөрес кулланылган; хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килә | Текст, гомумән алганда, логик эзлеклелектә төзелгән, ләкин логик бәйләнешләрдә ***һәм /яки*** абзацларга бүленештә ***яки*** хатның төзелешендә 1-2 төгәлсезлек бар | Текст төзелешендә логик эзлеклелек сакланмаган; язма текст төзелешендә 3 яки күбрәк хата бар, ***яки*** хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килми. |
| К3 | Текстның лексик-грамматик төзелеше | Коммуникатив бурычны үтәү өчен кирәк булган төрле лексик һәм грамматик чаралар файдаланылган (текстны аңлауга зыян китермәгән 1-2 төгәлсезлек рөхсәт ителә) | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (3-4 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***яки*** тел хаталары юк, ләкин артык гади лексик һәм грамматик чаралар кулланылган | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (5-6 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***һәм /яки*** текстны аңлауга зыян китерә торган 1-2 грамматик хата бар | Текстны аңлауга зыян китерә торган хаталар 6 дан күбрәк |
| К4 | Орфография һәм пунктуация | | Орфографик һәм пунктуацион хаталар юк, **яки** текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 1-2 хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 3-4 орфографик һәм пунктуацион хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерә торган орфографик һәм пунктуацион хаталар 4 тән күбрәк |

Шәхси хат язу биреме К1-К4 критерийлары буенча тикшерелә. Максималь **10 балл** алырга мөмкин.

Текстның эчтәлеге биремгә туры килмәсә (язма хат характерында булмаса, **тәкъдим ителгән сорауларга җавап урынына башка мәгълүмат язылса**, тәкъдим ителгән хат күчереп кенә язылса) бу бирем өчен 0 балл куела.

Хатның күләме 3**0** сүздән ким булса, К3 һәм К4 критерийлары буенча максималь балл куелмый.

Эшнең күләмен билгеләгәндә, беренче сүздән алып соңгысына кадәр (шулай ук адрес, язылу вакыты, имза да) исәпкә алына. **Хатта укучы үзенең чын исемен, адресын күрсәткән очракта эш тикшерелми.**

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0 - 12 балл – «2» ле билгесе;

13 - 22 балл – «3» ле билгесе;

23 - 33 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен (1-13 нче биремнәр) баллары 7 дән кимрәк булмаска тиеш. Әгәр укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 7 дән кимрәк булса, «3» ле билгесе куела.

34 - 46 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 10 нан кимрәк булмаска тиеш. Әгәр укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 10 нан кимрәк булса, «4» ле билгесе куела.